РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

«_24_» __июль_________ 2018 ел №_174__

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль район Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртипләре Кодексын яңа басмада раслау

Татарстан Республикасы Президентының 2014 нче елның 29 нче ноябрендә чыгарылган ПУ-1100 номерлы “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртипләре Кодексына үзгәрешләр кертү турындагы” Указын тормышка ашыру максатында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендәге рәсми сайтларында коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча бүлекләргә материаллар урнаштыруның бердәм таләпләрен раслау турында” 2013 нче елның 4 нче апрелендәге 225 нче карарын үтәү өчен, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР БИРӘ**:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртипләре Кодексын кушымта нигезендә яңа басмада расларга.

2. Чирмешән муниципаль районы Советының 2011 нче елның 25 нче февралендә 24 нче сан астында чыгарылган “Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районындагы Совет, Финанс-бюджет палатасы Башкарма комитеты, Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр Палатасы, Контроль-счет палатасы муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртипләре Кодексын раслау турындагы ” карарын (2014 нче елның 25 июлендә 227 нче сан астында һәм 2014 нче елның 17 нче декабрендә 268 нче сан астында Чирмешән муниципаль районы Советы карарына нигезләнеп кертелгән үзгәрешләр белән) көчен югалткан дип санарга.

3. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә җитәкчеләренә әлеге Кодекска таянып эш итәргә тәкъдим итәргә, муниципаль хезмәткәрләрне гамәлдәге карар белән таныштыруны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә хезмәтенә кергәндә хезмәт килешүнамәләренә Кодексны бозган очракта җаваплылык турындагы положениене кертергә.

5. Сайланма муниципаль вазифа башкаручы затларга әлеге Кодексның принципларын аларның хокукый статусларына каршы килмәүче өлешләрендә үтәргә тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

7. Әлеге карар аңа имза куелган көннән көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешенә җаваплылык Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Совет Аппараты җитәкчесенә йөкләтергә.

Муниципаль район Советы рәисе,
район башлыгы Ф.М. Дәүләтшин